СОВЕТ СТАРОЮРАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЮРАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

N 88 Иске Юраш авылы "15" май 2023 ел

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Иске Юраш авыл җирлеге Советының «Алабуга муниципаль районы Иске Юраш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында»2015 елның 15 июнендәге 193 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 26.01.2023 елдагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының "Иске Юраш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Иске Юраш авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. Иске Юраш авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге 193 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районының Иске Юраш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 23 бүлегенең 23.2 пунктындагы 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"а)Татарстан Республикасы Раис администрациясе;"»

1.2. Нигезләмәнең 23 бүлегенең 23.2 пунктындагы 3 пунктчасының 5 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзен «Татарстан Республикасы Раисы»сүзләре белән алыштырырга.

1.3. Нигезләмәнең 23 бүлегенең 23.2 пунктындагы 4 пунктчасының 4 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзен «Татарстан Республикасы Раисы»сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис Р. Г. Юнусов